**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 25 май № 343

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру регламентын раслау турында» 2016 ел, 14 март, 140 нчы карары белщн расланган Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру регламентына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру регламентын раслау турында» 2016 ел, 14 март, 140 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру регламентына, 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«6. Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру буенча чаралар үткәрү өчен Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзелә.

Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе составына түбәндәгеләр керә:

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры (Комиссия рәисе), Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары (Комиссия рәисе урынбасары);

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры билгеләгән Министрлыкның структур бүлекчәләре җитәкчеләре, белгечләре;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты вәкиле (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты вәкиле;

Муниципаль берәмлекләр советы рәисе (килешү буенча);

эшчәнлекләре дәүләт хезмәте белән бәйле булган фәнни оешмалар, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белемнең белем бирү оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары вәкиле (вәкилләре) (килешү буенча).

Комиссиянең сан һәм персональ составы, шулай ук эш тәртибе Министрлык боерыгы белән раслана.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков